**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.02.2021 Казан шәһ. № 274

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү Тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы белән расланган федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәнең 16 пунктындагы «б» пунктчасы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турындагы нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 19.10.2020 ел, № 1722 боерыгы белән расланган дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы комиссиясе турындагы нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасы белән б о е р а м:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү Тәртибен расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Министр М.Н. Садыйков

27.02.2021 № 274
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү Тәртибе ( алга таба - Тәртип), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар бүлегенә керү процедурасын регламентлый:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләп торган, әлеге вазифаларны биләгәндә Министрлык боерыгы белән расланган дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада хезмәт яки граждан-хокукый шартнамәсе шартларында эш башкаруга ризалык бирү турында, әгәр бу оешма белән дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазифа (хезмәт) бурычларына керсә, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көннән ике ел узганчы, мәгълүмат бирү мәҗбүри булган, граждан мөрәҗәгате;

Татарстан Республикасы Министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәренең (алга таба – дәүләт хезмәткәре) объектив сәбәпләр аркасында үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мөмкинлеге булмау турында белдерүе;

Дәүләт хезмәткәренең чит ил дәүләтенең территориясендәге счетлар (кертемнәр) булган, чит ил банкында һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклау гамәлгә ашырылуны әлеге чит ил дәүләтенең законнары нигезендә чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан салынган кулга алу, файдалануны тыю белән бәйле рәвештә, яисә аның ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле рәвештә «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау турында белдерүе.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәрнамәсен керү һәм карау тәртибе Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен раслау турында» 2016 елның 20 февралендәге 315 номерлы боерыгы белән җайга салына.

2. Граждан мөрәҗәгатьләре һәм дәүләт хезмәткәре гаризалары министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) министрлык эшләре белән идарә итүнең гомуми бүлеге аша язма рәвештә тапшырыла, аларның формасы әлеге Тәртипнең 1, 2 һәм 3 нче кушымталарында китерелгән.

3. Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) өч эш көне дәвамында Министрлыкта коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка (алга таба - җаваплы зат) алдан карау өчен мөрәҗәгать (гариза) җибәрә.

4. Мөрәҗәгатьне (гаризаны) алдан карау барышында җаваплы зат мөрәҗәгатьне (гаризаны) җибәргән гражданнан яисә дәүләт хезмәткәреннән анда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмаларны сорый.

5. Мөрәҗәгатьне (гаризаларны) алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат язмача дәлилләнгән бәяләмә әзерли. Мөрәҗәгать (гариза), граждан яисә дәүләт хезмәткәре мөрәҗәгатькә (гаризага) кушып бирелгән материаллар, алдан карау барышында (булганда) алынган аңлатмалар, шулай ук мөрәҗәгатьне (гаризаны) алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә мөрәҗәгать (гариза) алынган көннән җиде эш көне эчендә дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы комиссиясе рәисенә тапшырыла (алга таба - Комиссия).

6. Комиссия Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 19.10.2020 ел, № 1722 боерыгы белән расланган дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы комиссиясе турындагы Нигезләмә нигезендә мөрәҗәгать (гариза), аңлатмалар һәм башка материалларны карый.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт
тәртибенә карата таләпләрне үтәү
һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу
буенча комиссиясе утырышын
үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр,
гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү Тәртибенә
Кушымта №1

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрына

____________________________________________
(фамилия, инициаллар)

____________________________________________
(мөрәҗәгать итүче гражданның фамилиясе, исеме,

____________________________________________
атасының исеме (булса))

Гражданның яшәү урыны адресы: _____________
____________________________________________

Гражданның телефоны: ______________________
____________________________________________

Коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада хезмәт килешүе шартларында вазыйфа биләүгә йә коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга ризалык бирү турында
гариза

Мин, _________________________________________________________________________,
(фамилия, исем, атасы исеме (булса))
Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау Министрлыгында дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән ______________________________________________________________,
(вазыйфасы)
_________ ________ кадәр
(вакыт аралыгы)
«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы нигезендә ризалык бирүегезне сорыйм:

- вазыйфаны биләүгә:

__________________________________________________________________________________
(граждан биләргә планлаштырган вазыйфа исеме)
яки

- граждан-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга (хезмәт күрсәтүгә)___________________________________________________________________
(гражданин башкарачак эш төрләре, хезмәт күрсәтү атамасы)
_________________________________________________________________________________.
(коммерция оешмасы яки коммерцияле булмаган оешма исеме)

дәүләт граждан хезмәтенең күрсәтелгән вазыйфасын биләгәндә мин әлеге оешмага карата дәүләт идарәсенең* түбәндәге функцияләрен башкардым _______________________________________.
(күрсәтергә нинди)

__________________________________________________________________________________

Минем вазыйфаларыма керәчәк (минем башкарган эшем керәчәк): ___________________________________________________________________________

(граждан-хокукый шартнамә төзегәндә вазыйфаи бурычларны, характеры башкарыла торган эш

___________________________________________________________________________

кыскача тасвирламасы)

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм әлеге мөрәҗәгатьне караганда мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятләнәм /ниятләмим (кирәклесен астына сызарга).

Кабул ителгән карар турында мәгълүматны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм: ___________________________________________________________________________

(юллау ысулы күрсәтелә (почта аша, электрон рәвештә, электрон рәвештә алу һ. б.)),

___________________________________________________________________________

(әгәр юллау ысулы белән почта аша яки электрон рәвештә почта адресы яки электрон почта адресы күрсәтелә)

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ____________________ | ______________________________ |
| (дата) | (имза) | (имзаны киңәйтү) |

---

* оешма белән дәүләт, муниципаль (административ) идарә итү функцияләре - дәүләт яисә муниципаль хезмәткәр вәкаләтләре әлеге оешмага карата кадрлар, оештыру-техник, финанс, матди-техник яки башка мәсьәләләр буенча мәҗбүри карарлар кабул итәргә, шул исәптән әлеге оешма тарафыннан билгеле бер эшчәнлек төрен һәм (яки) аерым гамәлләрне гамәлгә ашыруга рөхсәтләр (лицензияләр) бирүгә бәйле карарлар кабул итәргә яисә мондый карарлар проектларын әзерләргә («коррупциягә каршы тору турында»25.12.2018 ел, № 273-ФЗ Федераль законның 1 статьясы).

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт
тәртибенә карата таләпләрне үтәү
һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу
буенча комиссиясе утырышын
үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр,
гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү Тәртибенә
Кушымта №2

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрына

________________________________________
(фамилиясе, инициаллар)

________________________________________
(мөрәҗәгать итүче гражданның фамилиясе-исеме)

________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең биләгән вазыйфасы)

Үземнең хатынымның (иремнең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны объектив сәбәпләр аркасында тапшыру мөмкинлеге булмау турында
гариза

Мин керем, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны тапшыру мөмкинлегем юк дип хәбәр итәм, үземнең______________________________
______________________________________________________________________
(хатыны, ире һәм (яки) балигъ булмаган балаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса)
______________________________________________________________________
балигъ булмаган балаларның туган көне)
сәбәбе: ____________________________________________________________
(Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең
______________________________________________________________________
хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе
______________________________________________________________________
мәгълүматларны тапшырмау объектив һәм ихтирамлы характерда булуы турында нәтиҗә ясый алырлык
______________________________________________________________________
барлык сәбәпләр һәм хәлләр күрсәтелә)

Гаризага түбәндәге материалларны кушам (булганда):
____________________________________________________________
(кушымта итеп бирелә торган материаллар күрсәтелә)

Күрсәтелгән мәгълүматларны бирү буенча дәүләт граждан хезмәткәрләренә кабул ителгән чаралар: __________________________________________________________

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм әлеге гаризаны караганда мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятләнәм / ниятләмим (*кирәклесен астына сызарга).*

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | _______________ | ____________________ |
| (дата) | (имза) | (имзаны киңәйтү) |

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт
тәртибенә карата таләпләрне үтәү
һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу
буенча комиссиясе утырышын
үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләр,
гаризалар һәм хәбәрнамәләр керү Тәртибенә
Кушымта №3

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрына

____________________________________________
(фамилиясе, инициаллар)

____________________________________________
(мөрәҗәгать итүче гражданның фамилиясе-исеме)

____________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең биләгән вазыйфасы)

«Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау турында гариза

Чит ил дәүләтенең территориясендәге счетлар (кертемнәр) булган, чит ил банкында һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклау гамәлгә ашырылуны әлеге чит ил дәүләтенең законнары нигезендә чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан салынган кулга алу, файдалануны тыю белән бәйле рәвештә, яисә аның ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле рәвештә «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше, 4 статьясындагы 3 өлеше таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау турында таләпләрен үтәү мөмкинлегем юк, дип хәбәр итәм. Сәбәпләре:

______________________________________________________________________________
(дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм

______________________________________________________________________________
мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы комиссиясе

______________________________________________________________________________
Федераль законның күрсәтелгән таләпләрен үтәмәүнең сәбәбе объектив һәм

______________________________________________________________________________
җитди характерга ия булуы турында нәтиҗә ясый алсын өчен кирәкле барлык сәбәпләр һәм шартлар күрсәтелә)

Гаризага түбәндәге материалларны кушам (булганда): ______________________________

______________________________________________________________________________
(кушымта итеп бирелә торган материаллар күрсәтелә)

Федераль законның күрсәтелгән таләпләрен үтәү өчен күрелгән чаралар:

___

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм әлеге гаризаны караганда мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятләнәм / ниятләмим (*кирәклесен астына сызарга)*.

| | | |
|---|---|---|
| __________________ | __________________ | __________________ |
| (дата) | (имза) | (имзаны киңәйтү) |